DOI: 10.26907/2311-2042-2023-20-1-182-188

# REVIEW OF TAGIR GILAZOV'S MONOGRAPH "TUKAY STUDIES: THE WAYS TO UNDERSTAND AND TO EXPLORE"

**Nurfiya Marsovna Yusupova,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
faikovich@mail.ru.

The article considers T. Gilazov's work "Tukay Studies: The Ways to Understand and to Explore" as an object of our review. The article clarifies the contribution of this scientific publication to the research into the life and work of Tukay. It states that the scholarly and critical literature, dedicated to the poet, is studied, on the one hand, in the national-public, Tatar spiritual-cultural and literary-aesthetic aspects; on the other hand, it is done in the context of Eastern and Western cultures. This determines the relevance and scientific novelty of the article. The article highlights the significance of the T. Gilazov's monographic work for literary science during the 20th–early 21st centuries. Firstly, this publication is a systemic research into the consistent, long-term, holistic development of Tukay studies, a comprehensive account of the trends reflecting its changes, transformations and the main stages of the poet's creativity development. Secondly, the article establishes that the systematic work on Tukay's studies reveals the turns in the development of Tatar literary and aesthetic thought and the history of literary criticism. Thirdly, the focus is on the fact that comprehensive work on Tukay studies, as a holistic system, can become a conceptual, methodological "key" to the study of the literary and historical heritage of other writers. Fourthly, the article argues that I. Nurullin's monograph, which determines the place held by the ideological and aesthetic representation of Tukay's spiritual heritage, made a significant contribution to literary criticism in historical and dialectical aspects.

**Key words**: Tagir Gilazov, Gabdulla Tukay, Ibragim Nurullin, Tukay, Tukay studies, poetry, Tatar literary criticism

The name and work of Gabdulla Tukay is constantly in the focus of the Tatar critical and spiritual thought. M. Khasanov, putting the poet on a par with Dante, Goethe, Byron, A. Pushkin, A. Mickiewicz, R. Tagore and T. Shevchenko, calls him "an encyclopedia of the Tatar life in the 20th century, a Tatar flower in the garden of world culture" [8, p. 4]. The attitude towards Tukay plays an important role in national self-determination, the life of the Tatar nation and the importance of the personality of Tukay. His work is a vivid encyclopedia of the Tatar people's historical, literary and cultural development, which determined the development of the literary and aesthetic thinking of the Tatars in the 20th century.

Kh. Usman, G. Khalit, Ya. Agishev, N. Yuziev, R. Nafigov, I. Nurullin, R. Ganiyeva, N. Laisov, Kh. Minnegulov, T. Galiullin, Z. Ramiev, Z. Mukhametshin and others creatively developed and enriched the ideas of such outstanding thinkers of the early 20th century as F. Amirkhan, J. Validi, G. Sagdi, G. Rakhim, and laid the foundation of Tukay studies. R. Gainanov, N. Yuziev, R. Dautov, Z. Ramiev, R. Islamov, J. Minnullin and others conduct extensive research on identifying the hidden signatures of the poet, his unknown poems, individual facts related to his life and work and on systematizing the obtained information. We can rightly call the chronicle of Tukay's life and work the era of scientific evaluation in accordance with the principles and regulations, preserved in the development of literary and aesthetic thinking in Tatar poetry.

The revival in the Tatar literary and aesthetic thought in the early 21st century has opened up new perspectives in Tukay studies, further expanding the scientific horizons: in 2015, owing to J. Minnullin and R. Islamov's efforts, two volumes of "Tukay – in Notes" were published in the series "Great Personalities", which familiarize the Tatar reader with many facts that have remained unknown until now or, for certain reasons, remained in the shadows ([6], [7]); the publication of Tukay's Encyclopedia in 2016 made it possible to present in one collection all the materials obtained over more than a hundred years of the poet's studies [1]; it was followed by the three-volume edition of "Materials for the Chronicle of Gabdulla Tukay's Life and Work", which was published in 2021. It contained a new interpretation of the poet's personality and work ([2], [3], [4]).

Despite this fact, the issue of generalization, scientific evaluation and critical interpretation of the poet's work in Tatar literature is still on the current agenda as a scientific trend. T. Gilazov's book "Tukay Studies: The Ways to Understand and to Explore", presented to the literary community in 2023, is perceived as a new stage in Tukay studies [5]: he attaches great importance to systematizing the study of Tukay's work, its comprehensive study in development and its evaluation on a conceptual basis.

It is of special importance for Tatar literature of the early 21st century. Firstly, this edition is a holistic system that consistently and completely studies the main stages of the Tukay studies development in the 20th and early 21st centuries. By evaluating the poet's life and work in a specific historical era, the scholar substantiates Tukay studies as a holistic scientific trend, thereby expanding the understanding of Tatar literature as a science.

In the first section of the monograph, the author considers Tukay studies in the 20th – early 21st centuries in chronological order and distinguishes four stages of research into Tukay's oeuvre: 1) the beginning of the 20th century; 2) 1920–50; 3) 1960–80; 4) the late 20th – the early 21st centuries. The section begins with the discussion of the fundamental questions of Tukay studies: "In what years did the study of Tukay begin? Under what conditions did the first knowledge and ideas about Tukay's work become an independent scientific trend? How was it connected with national-scientific views and the level of the aesthetic thinking development?" [5, p. 17]. Based on these questions, the work analyzes the critical recordings and publications of the early 20th century. Analyzing the publications of J. Validi, G. Iskhaki, F. Amirkhan, G. Ibragimov, G. Rakhim and others, T. Gilazov singles out the principles of nationalism and nationality of this period as the main principles for studying Tukay's work. Particular attention is paid to the personality and heritage of Amirkhan as the founder of Tukay studies [5, p. 19].

The years of 1920s–50s seem to be the most difficult and controversial period not only in Tukay studies, but generally, in literary criticism, literary and scientific thought. They were assessed, on the one hand, as an era of heated discussions, a clash of opinions and contradictory patterns in Tukay studies; on the other hand, it was a period of generalization of the poet's oeuvre and the time when his works were published. T. Gilazov research into the heritage of J. Validi, F. Burnashev, G. Sagdi, F. Saifi-Kazanly, G. Nigmati and G. Gali clarifies their contribution to the study of the poet's work.

The third stage in Tukay studies were the 1960s -80s, the formidable and tragic years when this research gained its scientific strength. These years, which gave Tatar literature such scientists as G. Khalit, I. Nurullin, Kh. Khismatullin, M. Gainullin, R. Nafigov, N. Khisamov, N. Laisov, R. Ganieva, Z. Ramiev, H. Minnegulov and T. Galiullin, are considered to be the period of the formation and development of "Tukay studies" and "Tukay science". Putting the focus of methodological issues on Tukay studies, T. Gilazov identifies that the poet's works were studied in their relation to Turkic literatures, Eastern and Western literary traditions. Based on the analysis of many articles and works, this idea sounds well-founded.

At the turn of the 20th –21st centuries, Tukay studies entered the period of new landmarks and significant qualitative changes. Summarizing opinions about this period, T. Gilazov writes: "The trend of comments on the spiritual heritage of the poet in the context of general Turkic literature is increasing. In the Tatar diaspora and in the foreign Tatar press, actions are being taken to return to the people the memoirs and articles dedicated to Tukay, which set out the principles and methods for evaluating the poet's oeuvre. Scientific textology of Tukay's works undergoes a great upsurge" [5, pp. 237–238]. The scholar focuses on the emergence of new scientific and methodological concepts in Tukay studies of this period, the discovery of new aspects in the study of the poet's work, in particular, on the close connection of his spiritual heritage with the Koran, with the culture of Islam, on a holistic system of comprehensive studies, conducted in the literature devoted to the image of Tukay. Objective assessments of the articles and publications, and their detailed analysis indicate that the author is a researcher possessing critical vision and thinking. As a result of his work on Tukay studies, which comprise the period of over more than a century, T. Gilazov argues that they contribute to the development of history, theory and criticism of Tatar literature, determining the possibilities for its revival, ways to reveal new qualities of national verbal art, enriching the literary historical and artistic thought with new results and generalizations.

As you can see, in the monograph, Tukay's work is studied in conjunction with the development of national literary and philosophical thinking, against the background of mutual influence; it is analyzed in conjunction with the passage of time

and the changes in philosophical, spiritual and aesthetic concepts. Thus, the trends and changes in Tukay studies in the 20th century make it possible to more profoundly understand the waves of the development of Tatar literary criticism, literary research, the literary-critical environment, and more vividly imagine a new movement in the development of literary and aesthetic thinking, and the history of literary criticism. Thus, the work clarifies the achievements gained in literary science and literary criticism, the scientific guidelines that were conditioned by the life and creative path of the poet, their causes and prerequisites. Moreover, it rebuilds separate assessments-relationships, the schemes of thought in literary research and literary criticism. Therefore, the study of the development of Tukay's work is the study of the process of Tatar literary criticism.

Thirdly, this work identifies the principles, rules, the methodological essence and conceptual possibilities for studying and evaluating Tukay's work. Therefore, a comprehensive analysis of Tukay studies as a holistic system, revealing the literary and aesthetic basis for studying the poet's work, can become a conceptual, methodological "key" for assessing the creative oeuvre of other writers.

Fourthly, the second part of the monograph focuses on the publication of I. Nurullin, related to the research into the work of G. Tukay, G. Iskhaki, the issues of scientific critical publications and literary theory. In this chapter, T. Gilazov comments on the work of I. Nurullin related to Tukay's work; T. Gilazov highlights I. Nurullin's contribution to the development of this scientific trend, the consolidation of his multifaceted activities and evaluation of the poet's work on a conceptual basis. Having analyzed I. Nurullin's scientific heritage, he concludes that the scholar was able to conceptually evaluate Tukay's work, and enrich Tukay studies with new fundamental views and assessments.

This publication, providing a large-scale study of research into Tukay's oeuvre, is devoid of all schematic reflections and strives for maximum objectivity, thus holding an important place in Tukay studies. We believe that this monograph, which is of great importance for conducting research on a conceptual basis, will be in great demand with Tatar readers and will become a handbook for those who study and love Tukay's work.

**References**

1. *Gabdulla Tukai. Ehntsiklopediya* (2016) [Gabdulla Tukay. Encyclopedia]. Gl. red. Z. Z. Ramiev. 864 p. Kazan', Institut yazyka, literatury i kul'tury im. G. Ibrahimov. (In Tatar)

2. *Gabdulla Tukainyң tormysh həm iҗçat khronikasy өchen materiallar: 3 kitapta* (2021) [Materials for the Chronicle of Gabdulla Tukay's Life and Work: In 3 Books]. Kn. 3: 1911–1913. M. I. Ibrahimov, L. R. Nadyrshina, Z. Z. Rəmiev, G. M. Khannanova, Ə. Kh. Alieva, I. K. Zahidullin, N. I. Tairov, M. A. Podol'skaya, E. K. Səlakhova, F. G. Fəizullina, E. M. Galimҗanova; M. I. Ibrahimov, L. R. Nadyrshina redaktsiyasendə. 368 b. Kazan'. (In Tatar)

3. *Gabdulla Tukainyң tormysh həm iҗçat khronikasy өchen materiallar: 3 kitapta* (2021) [Materials for the Chronicle of Gabdulla Tukay's Life and Work: In 3 Books]. Kn. 2: 1908–1910. M. I. Ibrahimov, L. R. Nadyrshina, Z. Z. Rəmiev, G. M. Khannanova, Ə. Kh. Alieva, I. K. Zahidullin, N. I. Tairov, M. A. Podol'skaya, E. K. Səlakhova, F. G. Fəizullina, E. M. Galimҗanova; M. I. Ibrahimov, L. R. Nadyrshina redaktsiyasendə. 344 p. Kazan'. (In Tatar)

4. *Gabdulla Tukainyң tormysh həm iҗçat khronikasy өchen materiallar: 3 kitapta* (2021) [Materials for the Chronicle of Gabdulla Tukay's Life and Work: In 3 Books]. Kn. 1: 1886–1907. Z. Z. Rəmiev, M. I. Ibrahimov, G. M. Khannanova, Ə. Kh. Alieva, N. Sh. Nasyibullina, R. F. Kharrasova, A. I. Əkhmətova; Z. Z. Rəmiev, M. I. Ibrahimov redaktsiyasendə. 448 p. Kazan'. (In Tatar)

5. Gyilaжev, T. Sh. (2023). *Tukai gyil'miyate: tөsheny həm өirəny yullary* [Tukay Studies: Ways to Understand and to Explore]. 244 b. Kazan', "Shkola" redaktsiya-nəshriyat yzəge. (In Tatar)

6. *Tukai yadkərlərdə: 2 tomda* (2015) [Tukay in Notes (In Written Monuments)]. Tөzychelər: R. F. Islamov, filologiya fənnəre doktory, Җ. S. Miңnullin, tarikh fənnəre kandidaty. 968 p. Kazan, Җyen. (In Tatar)

7. *Tukai v zapisyakh (v pamyatnikakh): v 2 tomakh* (2015) [Tukay in Notes (In Written Monuments)]. Tөzychelər: R. F. Islamov, filologiya fənnəre doktory, Җ. S. Miңnullin, tarikh fənnəre kandidaty. 720 b. Kazan', Җyen. (In Tatar)

8. Khəsənov, M. Kh. (1997). *Tukai turynda syz* [A Word about Tukay]. Tukai həm XX gasyr tatar mədəniyate: Shagyir'neң 110 ellygyna bagyshlangan khalykara konferentsiya materiallary. Pp. 3– 5. Kazan'. (In Tatar)

# ТАҺИР ГЫЙЛАҖЕВНЫҢ «ТУКАЙ ГЫЙЛЬМИЯТЕ: ТӨШЕНҮ ҺӘМ ӨЙРӘНҮ ЮЛЛАРЫ» МОНОГРАФИЯСЕНӘ (КАЗАН, 2023. 244 Б.) БӘЯЛӘМӘ

**Нурфия Марс кызы Юсупова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
faikovich@mail.ru.

Әлеге мәкалә Т. Гыйлаҗевның «Тукай гыйльмияте: төшенү һәм өйрәнү юллары» хезмәтен бәяләү объекты итеп ала. Тикшерү дәвамында фәнни басманың Тукай фәненә керткән өлеше тәгаенләнә, шагыйрьгә багышланган гыйльми-тәнкыйди әдәбиятның, бер яктан, милли-иҗтимагый, татар рухи-мәдәни, әдәби-эстетик җирлегендә, икенче яктан, Шәрык һәм Гареб мәдәниятләре контекстында тикшерелүе ассызыклана. Мәкаләнең актуальлеге һәм фәнни яңалыгы шуның белән билгеләнә. XX гасыр дәвамында – XXI гасыр башында Тукай фәненең торышына күзәтү ясалган Т. Гыйлаҗев монографик хезмәтенең кыйммәте, әдәбият фәне өчен әһәмияте аерып куела. Беренчедән, әлеге басманың эзлекле, дәвамлы, бөтенлекле төстә Тукай фәненең формалашуын, үзгәреш-яңарыш тенденцияләрен, төп үсеш баскычларын комплекслы өйрәнеп, тулы бер система буларак тәкъдим итүе ассызыклана. Икенчедән, Тукай гыйльмиятен системалы өйрәнүнең татар әдәби-эстетик фикере үсешендәге, әдәби тәнкыйть тарихындагы борылыш-үзгәрешләрне тагын бер кат төгәлләштерүе билгеләнә. Өченчедән, Тукай турындагы фәнне тулы бер система буларак комплексы тикшерүнең башка әдипләр мирасы хакындагы зур гыйльми-тәнкыйди, әдәби-тарихи катламны тикшерүгә концептуаль, методологик «ачкыч» була алуына басым ясала. Дүртенчедән, монографиянең И. Нуруллинның Тукай рухи мирасын идея-эстетик күзаллаудагы урынын билгеләве, аның киңкырлы эшчәнлеген тарихи һәм диалектик бәйләнештә тикшереп, концептуаль нигездә бәяләве белән дә әдәбият белеменә зур өлеш кертүе ачыклана.

**Төп төшенчәләр**: Таһир Гыйлаҗев, Габдулла Тукай, Ибраһим Нуруллин, Тукай гыйльмияте, поэзия, татар әдәбият белеме

Габдулла Тукай исеме һәм иҗаты татар тәнкыйди, нәзари фикеренең даими күз уңында тора. М. Хәсәнов шагыйрьне, Данте, Гете, Байрон, А. Пушкин, А. Мицкевич, Р. Тагор, Т. Шевченколар белән бер рәткә куеп, «XX гасыр татар тормышының энциклопедиясе, дөнья мәдәнияте бакчасындагы татар чәчәге» дип атый [8, 4 б.]. Шуңа Тукайга булган мөнәсәбәт татар милләтенең үзбилгеләнүендә, яшәешендә мөһим роль уйный, Тукай шәхесе, аның иҗаты татар халкы тарихының, әдәби һәм мәдәни үсешенең ачык энциклопедиясе, XX гасыр татар әдәби-эстетик фикере үсешен билгеләүче маягы булып тора.

XX гасыр дәвамында Тукай шигърияте һәм тормыш юлын өйрәнүгә Х. Госман, Г. Халит, Я. Агишев, Н. Юзиев, Р. Нәфигов, И. Нуруллин, Р. Ганиева, Н. Лаисов, Х. Миңнегулов, Т. Галиуллин, З. Рәмиев, З. Мөхәммәтшин һ.б. галимнәр зур өлеш кертә. Алар, XX йөз башында Ф. Әмирхан, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, Г. Рәхим кебек күренекле фикер ияләре әйткән карашларны иҗади үстереп, баетып, Тукай гыйльмиятен формалаштыра. Шагыйрьнең яшерен имзаларын, билгесез шигырьләрен, тормыш һәм иҗат юлына бәйле аерым фактларны ачыклауда, мәгълүматлар туплауда Р. Гайнанов, Н. Юзиев, Р. Даутов, З. Рәмиев, Р. Исламов, Җ. Миңнуллин, һ.б. киң фәнни эзләнүләр алып бара. Шуңа да XX гасырны Г. Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасын, татар шигърияте мәйданында тоткан урынын әдәби-эстетик фикер үсешендә калыплашкан принциплар һәм кануннар нигезендә гыйльми бәяләү дәвере дисәк тә ялгышмабыз.

XXI гасыр башы татар әдәби-эстетик фикерендәге яңарыш Тукай гыйльмиятенең яңа перспективаларын ачып, фәнни офыкларны тагын да киңәйтеп-төрлеләндереп җибәрде: 2015 елда Җ. Миңнуллин, Р. Исламов тырышлыгы белән «Шәхесләребез» сериясендә нәшер ителгән ике томлык «Тукай – ядкярләрдә» басмасы шагыйрь шәхесенә, иҗатына бәйле моңа кадәр билгеле булмаган яисә аерым сәбәпләр нәтиҗәсендә күләгәдә калган күп фактларны татар укучысына кайтарды ([6], [7]); 2016 елда Тукай

энциклопедиясенең басылып чыгуы шагыйрьне өйрәнү фәненең йөз елдан артык тарихына бәйле эзләнүләрне бер үремтәдә тупларга мөмкинлек бирде [1]; 2021 елда дөнья күргән өч томлык «Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар» басмасы да шушы юнәлешне дәвам итеп, шагыйрь шәхесенә һәм иҗатына яңа интерпретация тәкъдим итте ([2], [3], [4]).

Шулай булуга карамастан, әлегә кадәр татар әдәбият фәнендә шагыйрь иҗатын фәнни, тәнкыйди интерпретацияләү хасиятләрен гомумиләштереп өйрәнү, тулы бер фәнни юнәлеш буларак бәяләү көн тәртибендә кала килде. Т.Ш. Гыйлаҗевның 2023 елда әдәби җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителгән «Тукай гыйльмияте: төшенү һәм өйрәнү юллары» китабы Тукай фәнендә яңа сүз булып кабул ителде [5]: ул Тукай иҗатын өйрәнүләрне бер системага салуы, Тукай гыйльмиятен үсеш-үзгәрештә комплекслы өйрәнүе, концептуаль нигездә бәяләве белән зур әһәмияткә ия.

Ул XXI гасыр башы татар әдәбият фәне өчен аеруча кыйммәтле. Беренчедән, әлеге басма XX гасыр дәвамында һәм XXI гасыр башында Тукай фәненең формалашу, үзгәреш-яңарыш тенденцияләрен, төп үсеш баскычларын эзлекле, дәвамлы, бөтенлекле төстә өйрәнеп, тулы бер система буларак тәкъдим итә. Конкрет тарихи вакыт аралыгында шагыйрьнең тормыш юлын, аеруча иҗатын өйрәнү юлларын бәяләү аша ул Тукай гыйльмиятен концептуаль нигезгә ия аерым бер фәнни юнәлеш буларак нигезли, шуның белән татар әдәбият белеме хакындагы күзаллауларны, фикер-карашларны да киңәйтеп җибәрә.

Монографиянең беренче бүлегендә XX гасыр – XXI гасыр башында Тукай фәне чорларга бүленеп, хронологик эзлеклелектә тикшерелә һәм Тукай фәнендә дүрт этап аерып куела: 1) XX йөз башы; 2) 1920-50 еллар; 3) 1960-80 еллар; 4) XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы. Бүлек Тукай фәненең нигез ташларын барлау белән ачылып китә һәм «Тукай фәненең чишмә башы кайсы елларга туры килә? Тукай иҗаты хакында беренче белемнәр, күзаллауларның мөстәкыйль фәнгә әверелүе нинди шартларда бара? Ул милли нәзари-гыйльми карашлар, эстетик фикерләүнең үсеш дәрәҗәсе белән ничек бәйләнгән?» [5, 17 б.] кебек сорауларны үзәккә алып, XX йөз башындагы тәнкыйди язмаларга, басмаларга анализны көн тәртибенә куя. Җ. Вәлиди, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Рәхим һ.б. язмаларын анализлап, Т. Гыйлаҗев бу чорда Тукай иҗатын өйрәнүнең төп принциплары буларак миллилек, халыкчанлык һәм халыкчылык принципларын аерып куя. Тукай фәненә нигез салучы буларак Ф. Әмирхан шәхесенә һәм мирасына аерым игътибар бирә [5, 19 б.].

Тукай фәнендә генә түгел, гомумән, әдәби тәнкыйть, әдәби, фәнни фикер үсешендә иң катлаулы, каршылыклы чорны тәшкил иткән 1920-50 еллар, бер яктан, Тукай гыйльмиятендә кискен бәхәсләр, фикерләр көрәше, каршылыклы закончалыклар дәвере, икенче яктан, шагыйрь мирасын барлау, аны бастырып чыгару эше башланган чор буларак үз бәясен ала. Җ. Вәлиди, Ф. Бурнаш, Г. Сәгъди, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Нигъмәти, Г. Гали мирасын өйрәнеп, Т. Гыйлаҗев аларның шагыйрь иҗатын өйрәнүгә керткән өлешен тәгаенләштерә.

1960-80 еллар зилзиләле һәм дәһшәтле елларны үтеп, акыл егәрлеге, фәнни мая туплаган Тукай фәнендә өченче этап итеп аерып чыгарыла. Татар әдәбият фәненә Г. Халит, И. Нуруллин, Х. Хисмәтуллин, М. Гайнуллин, Р. Нәфыйгов, Н. Хисамов, Н. Лаисов, Р. Ганиева, З. Рәмиев, Х. Миңнегулов, Т. Галиуллин кебек тукайчы галимнәрне бүләк иткән бу еллар чын мәгънәсендә «Тукай гыйльмияте», «Тукай фәне» формалашкан һәм үсеш алган чор буларак анализлана. Тукай фәнендәге төп методологик мәсьәләрне көн тәртибенә куеп, Т. Гыйлаҗев бу дәвердә шагыйрь поэзиясенең тугандаш, төрки әдәбиятлар, көнчыгыш һәм көнбатыш әдәби традицияләре яктылыгында өйрәнелүенә басым ясый. Күпсанлы мәкалә, хезмәтләр нигезендә расланган әлеге фикер дәлилле яңгырый.

XX-XXI гасыр чиге Тукай фәнендә яңа ориентирлар калыплашкан, зур сыйфат үзгәрешләре аваз салган, Тукай фәнендә яңа исемнәр пәйда булган чор буларак бәяләнә. Бу чор турындагы фикерләрен гомумиләштереп, Т. Гыйлаҗев: «Шагыйрь рухи мирасын гомумтөрки әдәбият контекстында шәрехләү юнәлеше көчәя. Татар диаспорасында, чит ил татар матбугатында Тукайга багышланган истәлек-хатирәләрне, мәкаләләрне халыкка кайтару юнәлешендә, аларда шагыйрь иҗатын бәяләү принципларын һәм алымнарын шәрехләү юлында нәтиҗәле гамәлләр ясала. Тукайның фәнни текстологиясе зур күтәрелеш кичерә» [5, 237-238 б.], – дип нәтиҗә ясый.

Галим тарафыннан шушы чорда Тукай иҗатын өйрәнүдә яңа фәнни-методологик концепцияләрнең пәйда булуына, шагыйрь иҗатын өйрәнү юлында яңа аспектларның ачылуына, аерым алганда, Тукай рухи мирасының Коръән тәгълиматы, Ислам мәдәнияте белән тыгыз бәйләнешенә, әдәбиятта Тукай образының яктыртылышы тулы система буларак комплексны өйрәнелүенә басым ясала. Мәкалә, язмаларга объектив бәя, җентекле анализ авторның тәнкыйди күзаллауга, фикерләүгә ия тикшерүче-галим булуын дәлилли. Әнә шулай бер гасырдан артык вакыт аралыгында тупланган Тукай гыйльмиятен өйрәнү нәтиҗәсендә Т. Гыйлаҗев шуны раслый: Тукай фәне татар әдәбияты тарихы, теориясе һәм тәнкыйте тармаклары үсешенә этәргеч бирә, аның яңарыш мөмкинлекләрен, милли сүз сәнгатенең яңа сыйфатларын ачу юлларын билгели, әдәби-тарихи һәм нәзари фикерне яңадан-яңа нәтиҗәләр һәм гомумиләштерүләр белән баета.

Күренгәнчә, монографиядә Тукай иҗаты милли әдәби-фәлсәфи фикер үсеше белән янәшәлектә, үзара йогынты яссылыгында өйрәнелә, заман агышы, фәлсәфи, нәзари-эстетик концепцияләр үзгәреше белән бәйләнештә анализлана. Шул рәвешле, Тукай гыйльмиятендәге борылышлар-үзгәрешләр XX гасыр дәвамында татар әдәби тәнкыйтенең, әдәбият фәненең үсеш-үзгәреш дулкыннарын, әдәби-тәнкыйди мохитне тагын да тирәнрәк тоярга мөмкинлек бирә, әдәби-эстетик фикер үсешендәге, әдәби тәнкыйть тарихындагы яңарыш хәрәкәтен тагын да ачыграк күз алдына бастыра. Шуның белән ул әдәбият фәнендә, әдәби тәнкыйтьтә шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлына бәйле калыплашкан фикерләрнең, фәнни ориентирларның формалашуын яки үзгәрүен, аларның сәбәпләрен яки алшартларын төгәлләштерүгә ирешә. Алай гына да түгел, әдәбият фәнендә, әдәби тәнкыйтьтә формалашкан аерым бәя-мөнәсәбәтләрне, схематик фикерләрне дә үзгәртеп җибәрә. Шуңа да Тукай гыйльмияте үсешен өйрәнү ул татар әдәби тәнкыйтенең барышын өйрәнү дисәк тә һич ялгышмабыз.

Өченчедән, әлеге басма Тукай иҗатын өйрәнү һәм бәяләү принципларын, кагыйдәләрен, ысулларын, методологик асылын, концептуаль мөмкинлекләрен тәгаенләштерә. Шуңа да Тукай гыйльмиятен тулы бер система буларак комплексны тикшерү, шагыйрь иҗатын өйрәнүнең әдәби-эстетик җирлеген барлау башка әдипләр мирасы хакындагы зур фәнни-тәнкыйди катламны бәяләүгә дә концептуаль, методологик «ачкыч» була ала.

Дүртенчедән, монографиянең икенче бүлеге И. Нуруллинның Тукай, Г. Исхакый иҗатларын өйрәнүгә мөнәсәбәтле фәнни-тәнкыйди язмаларын, әдәбият теориясе мәсьәләләренә караган басмаларын тикшерү үзәгенә куя. Бу бүлектә Т. Гыйлаҗев И. Нуруллинның Тукай иҗатына бәйле хезмәтләрен шәрехләп, аның әлеге фәнни юнәлеш үсешенә керткән өлешен төгәлләштерүгә, киңкырлы эшчәнлеген бергә туплап, концептуаль нигездә бәяләүгә ирешә. И. Нуруллинның фәнни мирасын анализлау аша галимнең Тукай иҗатын концептуаль бәяли алуы, Тукай гыйльмиятен яңа фундаменталь карашлар, бәя-хөкемнәр белән баетуы хакында нәтиҗә ясала.

Шулай итеп, Тукай гыйльмиятен киң һәм масштаблы, киңкырлы өйрәнүгә юнәлтелгән, һәртөрле схематизмнардан арындырылган һәм мөмкин кадәр объективлыкка омтылган бу басма Тукай фәнендә әһәмиятле урын тота. Моңа кадәр дөнья күргән хезмәтләрне бер бәйләмгә туплавы, концептуаль нигездә өйрәнүе белән зур әһәмияткә ия булган бу монография татар укучылары арасында киң таралыр һәм Тукай иҗатын өйрәнүчеләрнең, гомумән, шагыйрь иҗатын яратучыларның өстәл китабына әверелер дип ышанабыз.

**Әдәбият**


1. Габдулла Тукай. Энциклопедия / [баш. мөх. З.З. Рәмиев]. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. 864 б.
2. Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар: 3 китапта. 3 китап: 1911–1913 = Материалы к хронике жизни и творчества Габдуллы Тукая: в 3 кн. Кн. 3: 1911–1913 / М. И. Ибраһимов, Л. Р. Надыршина, З. З. Рәмиев, Г. М. Ханнанова, Ә. Х. Алиева, И. К. Заһидуллин, Н. И. Таиров, М. А. Подольская, Э. К. Сәлахова, Ф. Г. Фәйзуллина, Э. М. Галимҗанова; М. И. Ибраһимов, Л. Р. Надыршина редакциясендә. Казань, 2021. 368 б.
3. Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар: 3 китапта. 2 китап: 1908–1910 = Материалы к хронике жизни и творчества Габдуллы Тукая: в 3 кн. Кн. 2: 1908–1910 / М. И. Ибраһимов, Л. Р. Надыршина, З. З. Рәмиев, Г. М. Ханнанова, Ә. Х. Алиева, Г. Ф. Төхфәтова; М. И. Ибраһимов, Л. Р. Надыршина редакциясендә. Казань, 2021. 344 б.
4. Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар: 3 китапта. 1 китап: 1886–1907 = Материалы к хронике жизни и творче-

ства Габдуллы Тукая: в 3 кн. Кн. 1: 1886–1907 / З. З. Рәмиев, М. И. Ибраһимов, Г. М. Ханнанова, Ә. Х. Алиева, Н.Ш. Насыйбуллина, Р. Ф. Харрасова, А. И. Әхмәтова; З. З. Рәмиев, М. И. Ибраһимов редакциясендә. Казань, 2021. 448 б.

5. *Гыйлаҗев Т. Ш.* Тукай гыйльмияте: төшенү һәм өйрәнү юллары. Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2023. 244 б.

6. Тукай ядкәрләрдә: 2 томда / Төзүчеләр: Р. Ф. Исламов, филология фәннәре докторы, Җ. С. Миңнуллин, тарих фәннәре кандидаты. Казан: Җыен, 2015. 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. 968 б.

7. Тукай ядкәрләрдә: 2 томда / Төзүчеләр: Р. Ф. Исламов, филология фәннәре докторы, Җ. С. Миңнуллин, тарих фәннәре кандидаты. Казан: Җыен, 2015. 2 т.: Мәкаләләр, шигырьләр, төрлеләр. 720 б.

8. *Хәсәнов М. Х.* Тукай турында сүз / Тукай һәм XX гасыр татар мәдәнияте: Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция материаллары. Казан, 1997. Б. 3– 5.

---

# РЕЦЕНЗИЯ НА МОНОГРАФИЮ ТАГИРА ГИЛАЗОВА «ТУКАЕВЕДЕНИЕ: ОСМЫСЛЕНИЕ И ПУТИ ИЗУЧЕНИЯ» (КАЗАНЬ, 2023. 224 С.)

**Нурфия Марсовна Юсупова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
faikovich@mail.ru.

Данная статья носит характер рецензии на монографию Тагира Гилазова «Тукаеведение: осмысление и пути изучения». В исследовании научно-критическая литература оценивается, с одной стороны, сквозь призму национально-общественной жизни, духовной атмосферы эпохи, с другой – в контексте восточной и западной культур. Новизна статьи состоит в выявлении вклада Т. Гилазова в тукаеведение и роли его монографии в истории татарской литературы. Ценность данного труда состоит в комплексном изучении тукаеведения от истоков до наших дней, в выявлении ключевых тенденций обновления, степеней роста. Уточняется роль тукаеведения в формировании литературно-эстетической мысли, истории литературной критики. В монографии сформирован методологический «ключ» к изучению целого научно-критического, литературно-исторического слоя других писателей, определен вклад И. Нуруллина в тукаеведение, теорию литературы, выявлена преемственность традиций.

**Ключевые слова:** Тагир Гилазов, Габдулла Тукай, Ибрагим Нуруллин, тукаеведение, поэзия, татарская литература, теория литературы